**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 11 июнь № 438

г. Казань

Татарстан Республикасын 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатына әзерләү буенча йөкләмәләрне үтәү планын раслау турында

«Россия-2018» заявкалар китабындагы һәм Татарстан Республикасына кагылышлы Россия Федерациясе йөкләмәләре исемлеген гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасын 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатына әзерләү буенча йөкләмәләрне үтәү планын (алга таба – План) расларга.

2. Россия-2018» заявкалар китабындагы һәм Татарстан Республикасына кагылышлы Россия Федерациясе йөкләмәләрен гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы министрлыкларына, ведомстволарына һәм оешмаларына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 көненә кадәр, Планны гамәлгә ашыру турында хисапны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 25 көненә кадәр, Планны гамәлгә ашыру барышы турындагы җыелма хисапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\438.doc